МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

24.01.2017 Казан ш. № 107-р

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 19.12.2015 № 3233-р карары белән расланган Газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләренә үзгәрешләр кертү һәм элегрәк аларга кергән җир кишәрлекләреннән чикләүләрне төшерү турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау турында карарлар кабул итү тәртибен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү турында” 30.04.2014 № 288 карарына туры китереп һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате һәм газ бүлү челтәрләренә милек хокукын раслаучы документлар нигезендә, һәм «Земля» РКҮ АҖ башкарган документациягә туры китереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Казан шәһәре территориясендә (Идел буе районы, Павлюхин ур. 2 нче номерлы трамвай паркы территориясе) урнашкан 23473 инвентарь номерлы җир асты газүткәргече өлешенә 28.03.2016 елда демонтаж ясалу сәбәпле 09.03.2016 елда дәүләт кадастр исәбенә куелган 16:50:070115:2256 кадастр номерлы җир кишәрлегендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт

мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының Казан шәһәре территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) чикләрен раслау турында” 19.12.2015 № 3233-р карары белән расланган (алга таба - № 3233-р Карар) 74 м озынлыктагы, гомуми мәйданы 296 кв.м булган газүткәргеч саклау зонасын туктатырга.

2. «Земля» РКҮ АҖ 2016 елның 1 декабрендә башкарган җир асты газүткәргечләренең зона чикләре урнашкан урынның текст һәм график тасвирламасында булган белешмәләр нигезендә, № 3233-р Карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Казан шәһәре территориясендә (Авиатөзелеш, Вахитов, Киров, Мәскәү, Яңа Савин, Идел буе, Совет районнары) 1 453,435 км озынлыктагы, гомуми мәйданы 6,053818 кв.км территорияне тәшкил иткән ЭПУ «Казаньгоргаз»ның әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән инвентарь номерлы газ бүлү челтәрләре (газүткәргечләр) чикләрен «Граница» кадастр үзәге» ҖЧҖ тарафыннан 2013 елның 1 октябреннән 2013 елның 15 декабренә кадәр башкарылган һәм 2013 елның 28 декабрендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ тарафыннан расланган җир өсте һәм җир асты объектларының саклау зоналары картасында (планында) булган белешмәләр нигезендә растарга.»;

3 пунктны көчен югалткан дип танырга;

1 кушымтада 614 юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 614 | 23473 | 15427 | Татарстан Республикасы,.Казан ш., Идел буе районы, Павлюхин ур. | 130,75 м | Урта басымлы җир асты газүткәргече, d=79; Урта басымлы җир асты газүткәргече, d=89; Түбән басымлы җир асты газүткәргече, d=114. | Милек хокукын регистрацияләү турында таныклык № 16-50.3-23.2001-1053.1 26.10.2001 |

3. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖга тәкъдим итергә:

1) газ бүлү челтәрләренең саклау зоналары турында аныкланган мәгълүматларны Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертү чараларын күрергә;

2) элек шушы җир кишәрлегендә булып, әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән җир асты газүткәргеченә демонтаж ясалу сәбәпле 16:50:070115:2256 кадастр номерлы җир кишәрлегенә мөнәсәбәтле чикләүләр

бетерелү буенча мәгълүматларны Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертү чараларын күрергә;

3) әлеге карар кабул ителүгә биш көн эчендә аны, карарның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән территорияне куллануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текст һәм график тасвирламасының электрон формасын, газүткәргечнең андый зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеген теркәп, демонтаж ясалу, газүткәргеч өлешләрен яңадан салу һәм техник хаталарны төзәтү сәбәпле, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газүткәргеч өлешләренең элек билгеләнгән саклау зоналары үзгәрүе турында белешмәләрне Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрына кертү өчен хокукларны регистрацияләү органына юлларга.

4. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны җир ресурслары идарәсе башлыгы Э.Г. Миндубаевка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**